| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.11.2019 г.Казань № 1031

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 24 декабрендә 6416 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының халыкка социаль ярдәм өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 15 ноябрендәге 1031 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә нурланыш авыруы һәм радиация йогынтысына яки техноген һәлакәтләрнең нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле башка авырулар алган яки кичергән гражданнарга, техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге инвалидларга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 16 июлендәге 566 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 11.07.2016 № 394, 08.06.2017 № 348, 07.05.2018 № 357, 19.09.2018 № 887, 26.07.2019 № 580 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә нурланыш авыруы һәм радиация йогынтысына яки техноген һәлакәтләрнең нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле башка авырулар алган яки кичергән гражданнарга, техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге инвалидларга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтының адресы, Министрлыкның һәм Идарәнең (бүлекнең) электрон почта адресы турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Идарәләрдә (бүлекләрдә) гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):»;

1.4.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.5 пунктның җиденче абзацында «РФ Президенты указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты указы» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктның икенче абзацында «арифметик хата» сүзләреннән соң «яки шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеле торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә нурланыш авыруы һәм радиация йогынтысына яки техноген һәлакәтләрнең нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле башка авырулар алган яки кичергән гражданнарга, техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге инвалидларга таныклык (таныклык дубликаты) (алга таба – таныклык (таныклык дубликаты) бирү | 1244-1 номерлы РФ Законының 15 ст. 4 п.;<br>Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы боерыгы белән расланган тәртип № 728 |
| 2.2. Башкарма хакимият органы исеме | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яисә шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) исеменнән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 728 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 3 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 728 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 2 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт | Таныклык бирү (таныклык бирүдән баш тарту турында) карар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар | Россия Гадәттән тыш хәлләр |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша рәсми мөрәҗәгать җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап 15 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң 20 эш көненә кадәр озайтыла.<br>Таныклык (таныклык дубликаты) бирү гариза бирүче таныклык артыннан килгән көнне гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы Россия Федерациясе законнарында каралмаган | министрлыгының 728 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 8 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон формадагыларын да, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Таныклык алу өчен:<br>Техноген һәлакәтләр («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария) нәтиҗәсендә нурланыш авыруы һәм радиация йогынтысына яки техноген һәлакәтләрнең («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария) нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле башка авырулар алган яки кичергән гражданнарга, техноген һәлакәтләр («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария) нәтиҗәсендәге инвалидларга таныклык бирү турында гариза (гаризаның киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән).<br>Әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы «а» - «д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:<br>радиоактив пычрану зонасында яшәү (хәрби яки аңа тиңләштерелгән хезмәт үтү), радиоактив пычрану зонасыннан эвакуацияләнү яки күченү фактын раслый торган билгеләнгән үрнәктәге таныклык яки белешмә:<br>Чернобыль АЭС һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәләрен бетерү) эшләрендә катнашу фактын раслый торган билгеләнгән үрнәктәге таныклык;<br>барлыкка килгән авруларның һәм инвалидлыкның Чернобыль | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 728 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 4, 5 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | һәлакәте («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария) нәтиҗәсендәге радиация йогынтысы белән бәйләнеше турында ведомствоара эксперт советы яисә хәрби-табиблык комиссиясе бәяләмәсе;<br>гариза бирүченең 3 х 4 см зурлыгындагы фотосы;<br>инвалидлыкны билгеләү фактын раслаучы федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениесе белешмәсе (инвалидлар өчен).<br>Әлеге Регламентның 1.2 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:<br>элегрәк яки Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 728 номерлы боерыгы белән расланган тәртип нигезендә бирелгән үлгән гражданин таныклыгы (аны югалткан очракта, үлгән гражданинның шәхси эшендә булган беренче документлары нигезендә бирелә);<br>бергә яшәү фактын раслый торган документлар (кирәк булган очракта).<br>Кирәк булган очракларда гражданнар әлеге таныклыкны алу хокукына ия булган зат белән туганлык элемтәләрен раслаучы документларны; тиешле тәртиптә бирелгән таныклык алуга ышаныч кәгазен; уллыкка алу турында таныклыкны; шәхесне раслаучы һәм гражданлыкка күрсәтә торган башка документларны тапшыра.<br>Таныклык дубликатын алу өчен:<br>Техноген һәлакәтләр («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария) нәтиҗәсендә нурланыш авыруы һәм радиация йогынтысына яки техноген һәлакәтләрнең («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария) нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле башка авырулар алган яки кичергән гражданнарга, техноген һәлакәтләр («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария) нәтиҗәсендәге инвалидларга таныклык бирү турында гариза (гаризаның киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән);<br>гариза бирүченең 3 х 4 см зурлыгында фотосы (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы «а» - «д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар | |

| | | |
|---|---|---|
| | өчен).<br>Элегрәк бирелгән таныклык яраксызга чыккан очракта, бозылган таныклык та тапшырыла.<br>Гариза бирүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:<br>югалган таныклыкның табылмавын раслаучы белешмә (эчке эшләр органнарыннан соратыла);<br>Россия Федерациясе Пенсия фонды территориаль органыннан пенсия | 143-ФЗ номерлы федераль закон;<br>Россия Гадәттән тыш хәлләр |

| | | |
|---|---|---|
| органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | алу факты турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фонды территориаль органыннан соратыла);<br>балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (гражданлык хәле актларын теркәү органнарында);<br>гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (гражданлык хәле актларын теркәү органнары органнарыннан соратыла);<br>тукландыручыны югалту турында белешмәләр (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан соратыла);<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.<br>Күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры да алынырга мөмкин, шул исәптән мондый мөмкинлек булганда – электрон рәвештә.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Гариза бирүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз ихтыяры белән дә тапшырырга хокуклы.<br>Аталган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Идарә (бүлек) гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы | министрлыгының 728 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 12 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.<br>3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булуы. | |

| | | |
|---|---|---|
| | 4. Гариза бирүченең яшәү урынына караган Идарәгә (бүлеккә) мөрәҗәгать итүе. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Ялган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торучы документларны тапшыру дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыт | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Идарә (бүлек) биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында | 880 номерлы Тәртипнең 2.4 п., Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүченең ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен гариза бирүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән хезмәттәшлек итүе саны;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен алу өчен зарури гариза белән документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче | |

| | | |
|---|---|---|
| | тарафыннан Министрлык сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Идарәгә (бүлеккә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, Идарәгә (бүлеккә) гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш | 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары»; |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.2 пунктның дүртенче абзацында «2.8» саннарын «2.7» саннарына алмаштырырга;

3.4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия фондыннан – хосусый шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр).»;

3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Идарәдә (бүлектә) булмаганда, Идарә (бүлек) белгече, шул исәптән электрон рәвештә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Россия Федерациясе Пенсия фонды территориаль органына дәүләт хезмәтен алучыга пенсия билгеләү турында;

балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан;

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнары органнарыннан соратыла);

тукландыручының вафат булуы турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан соратыла);

эчке эшләр органнарыннан югалган таныклыкның табылмавын раслаучы белешмәләрне (мөрәҗәгать итүче таныклык дубликатын алу буенча мөрәҗәгать иткән очракта);

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан – хосусый шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр).»;

3.5.1 пунктта һәм аннан соң текст буенча «вакыттан башлап» сүзләрен «көннән башлап» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.1 пунктның алтынчы абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.6.2 пунктта:

өченче абзацта «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта һәм аннан соң алга таба текст буенча «министр урынбасары» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларын кулланып, «министр» сүзенә алмаштырырга;

3.6.4 пунктның бишенче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.8 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.9 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«3.9. Техник хата төзәтү

Элек бирелгән таныклыкта (таныклык дубликатында) җибәрелгән техник хаталарны бетерүгә бәйле рәвештә таныклыкны (таныклык дубликатын) яңадан рәсмиләштерү техник хатасы булган, Идарә (бүлек) белгече тарафыннан гариза килгән көнне кабул ителгән һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәлгән таныклык (таныклык дубликаты) белән бергә тапшырылган гариза (киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.9.1. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турындагы үтенеч кәгазен Министрлыкка җибәрү

Идарә (бүлек) белгече гариза һәм техник хатасы булган таныклык (таныклык дубликаты) нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

таныклык (таныклык дубликаты) бирүгә исемлек (алга таба – исемлек) формалаштыра (Исемлекнең формасы Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 728 номерлы боерыгы белән расланган нигезләмәнең 3 нче кушымтасында китерелгән);

таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенеч кәгазе проектын әзерли (алга таба– үтенеч кәгазе);

Идарә (бүлек) җитәкчесенә кул кую өчен гаризаны һәм исемлек проектын җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенеч проекты, исемлек.

3.9.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе гаризаны һәм техник хатасы булган таныклыкны (таныклык дубликатын) караганнан соң, таныклык (таныклык дубликатын) бирү турындагы үтенеч кәгазенә һәм исемлеккә кул куя.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында имзаланган үтенеч кәгазе һәм исемлек.

3.9.3. Идарә (бүлек) белгече таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында гаризаны һәм исемлекне Министрлыкка юллый.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкка юлланган, таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенеч язуы һәм, техник хатасы булган таныклыкны (таныклык дубликатын) теркәп, исемлек

3.9.4. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар кабул итү

Министрлыкның эш башкару бүлеге белгече Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон Хөкүмәт» электрон документлар әйләнеше системасында Идарәдән (бүлектән) кергән үтенечне терки һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Идарәдән (бүлектән) документлар кергән көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: үтенеч, таныклык бланкы теркәлгән исемлек.

3.9.5. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар проектын рәсмиләштерә;

таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар проектын имзалау өчен министрга җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар Министрлыкта үтенеч теркәлгән көннән соң сигез эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар проекты.

3.9.6. Алга таба административ процедуралар әлеге Регламентның 3.6.5 - 3.6.10, 3.7.1 - 3.7.2 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлектә:

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору Министрлыкның социаль ярдәм чаралары методолгиясе бүлеге җитәкчесе, Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләре үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«4.2. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Идарә (бүлек) хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

кушымтаны (белешмәлекне) яңа редакциядә бәян итәргә:

«Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә нурланыш авыруы һәм радиация йогынтысына яки техноген һәлакәтләрнең нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле башка авырулар алган яки кичергән гражданнарга, техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге инвалидларга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең

административ регламентына кушымта
(белешмәлек)»

Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә нурланыш авыруы һәм радиация йогынтысына яки техноген һәлакәтләрнең нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле башка авырулар алган яки кичергән гражданнарга, техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге инвалидларга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы булган органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр»

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85551)<br>2-10-86<br>2-11-53 | Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85592)<br>7-25-10<br>7-14-25 | Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84344)<br>2-92-72<br>2-92-74 | Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85552)<br>3-11-46<br>3-12-81 | Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84341)<br>2-41-40<br>2-46-46 | Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84346)<br>2-08-90<br>2-08-80 | Usz.Alkeevo@tatar.ru |
| Әлмәт муниципаль районы социаль яклау идарәсе җитәкчесе | (8553)<br>32-45-50<br>43-82-15 | Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84376)<br>2-12-84<br>2-10-81 | Usz.Apastovo@tatar.ru |
| Арча муниципаль районында социаль | (84366) | Usz.Arsk@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| яклау бүлеге җитәкчесе | 3-13-53<br>3-13-33 | |
| Әтнә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84369)<br>2-16-60<br>2-10-84 | Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85569)<br>5-10-50<br>5-66-81 | 423930, г. Бавлы, пл. Победы, д. 4<br>Usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84368)<br>2-44-78<br>2-42-09<br>2-50-57<br>2-40-60 | Usz.Baltasi@tatar.ru |
| Бөгелмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85594)<br>6-50-44<br>6-55-70 | Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84374)<br>3-32-10<br>3-55-29 | Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84379)<br>2-17-57<br>2-22-76 | Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84365)<br>7-47-69<br>7-47-89 | Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84375)<br>2-38-07<br>2-30-07 | Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85557)<br>7-84-66<br>7-86-91 | Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85558)<br>7-10-64<br>7-09-76<br>3-26-89 | Usz.Zainsk@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Зеленодольск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84371)<br>5-58-80<br>4-16-62<br>4-22-97 | Usz.Zeldol@tatar.ru |
| Кайбыч муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84370)<br>2-11-12<br>2-15-57 | Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама Тамагы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-69 | Usz.K-uste@tatar.ru |
| Кукмара муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84378)<br>2-49-70<br>2-47-31 | Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85595)<br>5-07-51<br>5-50-03 | Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85563)<br>3-12-36<br>3-19-69 | Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85549)<br>2-23-00 | Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85555)<br>3-26-59<br>3-19-08 | Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85556)<br>2-57-37<br>2-57-69 | Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә социаль яклау идарәсе җитәкчесе | (8552)<br>53-60-33 | Usz.Chelny@tatar.ru |
| Түбән Кама муниципаль районы социаль яклау идарәсе җитәкчесе | (8555)<br>45-39-20<br>45-43-86 | Usz.Nizhnekamck@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| | 45-43-88<br>45-35-02 | |
| Яңа Чишмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84348)<br>2-41-18<br>2-41-42 | Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84345)<br>2-06-62<br>2-06-81<br>2-39-88 | Usz.Nurlat@tatar.ru |
| Питрәч муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84367)<br>3-06-68<br>3-02-78<br>3-00-15 | Usz.Pitriash@tatar.ru |
| Балык Бистәсе муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84361)<br>2-11-57<br>2-39-62 | Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84362)<br>2-28-11<br>2-28-55 | Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85559)<br>2-45-72<br>2-44-37<br>2-49-87 | Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84347)<br>3-00-00<br>3-08-98 | Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84373)<br>2-62-31 | Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районының социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (8552)<br>70-00-57<br>70-13-41 | Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84360)<br>2-18-56 | Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84396)<br>2-57-05<br>2-29-38 | Usz.Cheremshan@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Чистай муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84342)<br>5-55-73<br>5-12-06 | Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85593)<br>2-60-41<br>2-82-91 | Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Авиатөзелеш, Яңа Савин районнарында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843)<br>571-58-00<br>(843) 523-3-20 | Usz.Avia@tatar.ru<br>Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Вахитов, Идел буе муниципаль берәмлегенең социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843)<br>238-65-79<br>(843)<br>224-04-20<br>224-20-28 | Usz.Vahit@tatar.ru<br>Usz.Priv@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Киров, Мәскәү районнарында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843)<br>554-25-23 | Usz.Kirov@tatar.ru<br>Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Совет районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843)<br>272-51-79<br>273-18-06 | Msz.SovOR@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларына аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе җитәкчесе | 264-77-29 | pisma@tatar.ru». |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 16 июлендәге 567 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 18.01.2013 № 20, 07.06.2016 № 317, 10.10.2016 № 573, 08.06.2017 № 348, 07.05.2018 № 357, 19.09.2018 № 887, 26.07.2019 № 580 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтының адресы, Министрлыкның һәм Идарәнең (бүлекнең) электрон почта адресы турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Идарәләрдә (бүлекләрдә) гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре);

1.4.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.5 пунктта:

алтынчы-тугызынчы абзацта «РФ Президенты» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «РФ ГТХМ» сүзләрен «Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «яки шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) (алга таба – таныклык (таныклык дубликаты) бирү | 210-ФЗ номерлы федераль законның 5 ст.;<br>Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 540 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 2 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимият органы исеме | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яисә шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) исеменнән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 540 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 3 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 540 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 2, 5, 6 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Таныклык бирү (таныклык бирүдән баш тарту турында) карар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша рәсми мөрәҗәгать җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап 11 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң 16 эш көненә кадәр озайтыла.<br>Таныклыклар Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы (алга таба – Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы) тарафыннан, министрлыктан таныклыклар рәсмиләштерү һәм бирү турында күрсәтмәләр алынганнан соң ике ай эчендә рәсмиләштерелә.<br>Таныклык (таныклык дубликаты) бирү гариза бирүче таныклык артыннан килгән көнне гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы Россия Федерациясе законнарында каралмаган | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 540 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 4, 5 пунктлары |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм кирәкле хезмәтләрне күрсәтү өчен мәҗбүри булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, | Таныклык алу өчен:<br>1. Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык бирү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка карата 1 нче кушымтада китерелде.<br>2. Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган торак пунктлар исемлекләренә кертелгән торак пунктта яшәү фактын раслый торган документ (торак-эксплуатация идарәләре (торак-коммуналь бүлекләре) архивларыннан өземтәләр, паспорт өстәлләре белешмәләре, белем | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 540 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 3 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | бирү учреждениеләре архивларыннан бирелгән белешмәләр яисә исемлекләргә кертелгән торак пунктларда яшәү фактын раслый торган башка документлар).<br>Хәрби хезмәткәрләр өстәмә рәвештә, хәрби частьләрнең урнашу урыннарын күрсәтеп, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы архивларыннан билгеләнгән тәртиптә бирелгән архив документларын тапшыра.<br>Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары тиешле чорда хәрби частьнең хәрби шәһәрчегендә яшәү (яшәмәү) турында өстәмә архив белешмәләрен тапшыра.<br>Таныклык дубликатын алу өчен:<br>1. Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык дубликаты бирү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка карата 2 нче кушымтада китерелде.<br>Элегрәк бирелгән таныклык яраксызга чыккан очракта, бозылган таныклык та тапшырыла.<br>Гариза бирүче Россия Федерациясе гражданины паспортын күрсәтә.<br>Гариза бирүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) хезмәткәре | |

| | | |
|---|---|---|
| | тарафыннан таныклана. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына: гражданин тарафыннан Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлекләргә кертелгән торак пунктларда әлеге торак пунктка радиация йогынтысын күрсәткән, атом-төш сынаулары үткәрелгән көнгә кертелмәгән чорда яшәү турындагы документларны тапшырганда, Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында алынган суммар (тупланган) нурланыш дозасы турында бәяләмә (алга таба – бәяләмә) (бәяләмә формасы Россия | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 540 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 3, 6 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 540 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 2 номерлы кушымтасында китерелгән) (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 634 номерлы карары белән расланган кагыйдәләр нигезендә билгеләнә торган оешмадан соратыла);<br>югалган таныклыкның табылмавын раслаучы белешмә (эчке эшләр органнарыннан соратыла);<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләрне раслый торган документлар (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>Күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры да алынырга мөмкин, шул исәптән мондый мөмкинлек булганда – электрон рәвештә.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Гариза бирүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз ихтыяры белән дә тапшырырга хокуклы.<br>Аталган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Идарә (бүлек) гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел: | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.<br>3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, | |

| | | |
|---|---|---|
| | сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булуы.<br>4. Гариза бирүченең яшәү урынына караган Идарәгә (бүлеккә) мөрәҗәгать итүе.<br>5. Почта аша кергән гаризага теркәлеп бирелә торган билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган документларны тапшыру. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Гариза бирүче тарафыннан ялган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торган документларны тапшыру дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булып тора | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы һәм хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү чоры һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле | |

| | | |
|---|---|---|
| көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның исемлеге урнаштырылган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр. Шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә дә. | мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Идарәләрнең (бүлекләрнең) җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, | 880 номерлы ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 2.4 п.;<br>Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүматны алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтен алу турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән дә, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында тулы мәгълүматларның булуы;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы,<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Идарә (бүлек) белгечләренең Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән хезмәттәшлек итүе саны;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып | |

| | | |
|---|---|---|
| | эшләү урыннары аша дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гариза тапшыруны кертеп, дәүләт хезмәте дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлык сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Идарәгә (бүлеккә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, Идарәгә (бүлеккә) гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш. | Нигезләмәнең 10, 11 пункты; 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты; 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары;» |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.2 пунктның дүртенче абзацында «2.8» саннарын «2.7» саннарына алмаштырырга;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

Идарә (бүлек) белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәгеләрнең тапшырылуы турында, шул исәптән электрон рәвештә, рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында алынган суммар (тупланган) нурланыш дозасы турында бәяләмә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 634 номерлы карары белән расланган кагыйдәләр нигезендә билгеләнә торган оешмадан соратып алына) Министрлыкның социаль ярдәм күрсәтү чаралары методологиясе бүлеге белгече белән килештерү буенча (алга таба – Бүлек);

Эчке эшләр органнарыннан югалган таныклыкның табылмавын раслый торган белешмәләр;

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләрне раслый торган документлар – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.5.1 пунктта һәм аннан соң текст буенча «вакыттан башлап» сүзләрен «көннән башлап» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.1 пунктының өченче абзацында һәм аннан соң «РФ ГХМ» сүзләрен «Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.1 пунктның алтынчы абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.6.3 пунктының өченче абзацында һәм 3.6.6 пунктының өченче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.8 пункт үз көчен югалткан дип танырга:

3.9 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«3.9. Техник хата төзәтү

Элек бирелгән таныклыкта (таныклык дубликатында) җибәрелгән техник хаталарны бетерүгә бәйле рәвештә таныклыкны (таныклык дубликатын) яңадан рәсмиләштерү техник хатасы булган, Идарә (бүлек) белгече тарафыннан гариза килгән көнне кабул ителгән һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәлгән таныклык (таныклык дубликаты) белән бергә тапшырылган

гариза (киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.9.1. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турындагы үтенеч кәгазен Министрлыкка җибәрү

Идарә (бүлек) белгече гариза һәм техник хатасы булган таныклык (таныклык дубликаты) нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны исәпкә алу реестрын (алга таба – реестр) формалаштыру (Реестр формасы Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 540 номерлы боерыгы белән расланган тәртипкә 3 нче кушымтада китерелгән);

таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенеч кәгазе проектын әзерли (алга таба– үтенеч кәгазе);

Идарә (бүлек) җитәкчесенә кул кую өчен гаризаны һәм реестр проектын җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенеч проекты, реестр.

3.9.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе гаризаны һәм техник хатасы булган таныклыкны (таныклык дубликатын) караганнан соң, таныклык (таныклык дубликатын) бирү турындагы үтенеч кәгазенә һәм реестрга кул куя.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында имзаланган үтенеч кәгазе һәм реестр.

3.9.3. Идарә (бүлек) белгече таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында гаризаны һәм реестрны Министрлыкка юллый.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкка юлланган, таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенеч язуы һәм, техник хатасы булган таныклыкны (таныклык дубликатын) теркәп, реестр.

3.9.4. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар кабул итү

Министрлыкның эш башкару бүлеге белгече Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон Хөкүмәт» электрон документлар әйләнеше системасында Идарәдән (бүлектән) кергән үтенечне терки һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Идарәдән (бүлектән) документлар кергән көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: үтенеч, таныклык бланкы теркәлгән исемлек.

3.9.5. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар проектын рәсмиләштерә;

таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар проектын имзалау өчен министрга җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар Министрлыкта үтенеч теркәлгән көннән соң сигез эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар проекты.

3.9.6. Алга таба административ процедуралар әлеге Регламентның 3.6.5 - 3.6.10, 3.7.1 - 3.7.2 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлектә:

4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору Министрлыкның социаль ярдәм чаралары методолгиясе бүлеге җитәкчесе, Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләре үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Идарә (бүлек) хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.8 пунктта «хезмәткәр» сүзен «Учреждение белгече» сүзләренә алмаштырырга;

кушымтаны (белешмәлекне) түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

«Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85551)<br>2-10-86<br>2-11-53 | Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85592)<br>7-25-10<br>7-14-25 | Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84344)<br>2-92-72<br>2-92-74 | Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85552)<br>3-11-46<br>3-12-81 | Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84341)<br>2-41-40<br>2-46-46 | Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84346)<br>2-08-90<br>2-08-80 | Usz.Alkeevo@tatar.ru |
| Әлмәт муниципаль районы социаль яклау идарәсе җитәкчесе | (8553)<br>32-45-50<br>43-82-15 | Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84376)<br>2-12-84<br>2-10-81 | Usz.Apastovo@tatar.ru |
| Арча муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84366)<br>3-13-53<br>3-13-33 | Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84369)<br>2-16-60<br>2-10-84 | Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85569)<br>5-10-50<br>5-66-81 | 423930, г. Бавлы, пл. Победы, д. 4<br>Usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районында | (84368) | Usz.Baltasi@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| социаль яклау бүлеге җитәкчесе | 2-44-78<br>2-42-09<br>2-50-57<br>2-40-60 | |
| Бөгелмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85594)<br>6-50-44<br>6-55-70 | Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84374)<br>3-32-10<br>3-55-29 | Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84379)<br>2-17-57<br>2-22-76 | Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84365)<br>7-47-69<br>7-47-89 | Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84375)<br>2-38-07<br>2-30-07 | Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85557)<br>7-84-66<br>7-86-91 | Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85558)<br>7-10-64<br>7-09-76<br>3-26-89 | Usz.Zainsk@tatar.ru |
| Зеленодольск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84371)<br>5-58-80<br>4-16-62<br>4-22-97 | Usz.Zeldol@tatar.ru |
| Кайбыч муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84370)<br>2-11-12<br>2-15-57 | Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама Тамагы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-69 | Usz.K-uste@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Кукмара муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84378)<br>2-49-70<br>2-47-31 | Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85595)<br>5-07-51<br>5-50-03 | Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85563)<br>3-12-36<br>3-19-69 | Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85549)<br>2-23-00 | Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85555)<br>3-26-59<br>3-19-08 | Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85556)<br>2-57-37<br>2-57-69 | Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә социаль яклау идарәсе җитәкчесе | (8552)<br>53-60-33 | Usz.Chelny@tatar.ru |
| Түбән Кама муниципаль районы социаль яклау идарәсе җитәкчесе | (8555)<br>45-39-20<br>45-43-86<br>45-43-88<br>45-35-02 | Usz.Nizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84348)<br>2-41-18<br>2-41-42 | Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84345)<br>2-06-62<br>2-06-81<br>2-39-88 | Usz.Nurlat@tatar.ru |
| Питрәч муниципаль районында | (84367) | Usz.Pitriash@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| социаль яклау бүлеге җитәкчесе | 3-06-68<br>3-02-78<br>3-00-15 | |
| Балык Бистәсе муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84361)<br>2-11-57<br>2-39-62 | Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84362)<br>2-28-11<br>2-28-55 | Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85559)<br>2-45-72<br>2-44-37<br>2-49-87 | Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84347)<br>3-00-00<br>3-08-98 | Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84373)<br>2-62-31 | Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районының социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (8552)<br>70-00-57<br>70-13-41 | Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84360)<br>2-18-56 | Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84396)<br>2-57-05<br>2-29-38 | Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84342)<br>5-55-73<br>5-12-06 | Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85593)<br>2-60-41<br>2-82-91 | Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Авиатөзелеш, Яңа Савин районнарында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843)<br>571-58-00<br>(843) 523-3-20 | Usz.Avia@tatar.ru<br>Usz.Novosavin@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Вахитов, Идел буе муниципаль берәмлегенең социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843) 238-65-79 (843) 224-04-20 224-20-28 | Usz.Vahit@tatar.ru Usz.Priv@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Киров, Мәскәү районнарында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843) 554-25-23 | Usz.Kirov@tatar.ru Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Совет районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843) 272-51-79 273-18-06 | Msz.SovOR@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларына аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе җитәкчесе | 264-77-29 | pisma@tatar.ru». |

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга бердәй үрнәктәге махсус таныклыклар (таныклыклар дубликатларын) бирү буенча дәүләт хезмәте

күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2012 елның 19 июлендәге 574 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 26.07.2016 № 439, 08.06.2017 №348, 07.05.2018 №357, 19.09.2018 № 887, 26.07.2019 №580 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга бердәй үрнәктәге махсус таныклыклар (таныклыклар дубликатларын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4.1 пунктчаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтының адресы, Министрлыкның һәм Идарәнең (бүлекнең) электрон почта адресы турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Идарәләрдә (бүлекләрдә) гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):»;

1.4.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.5 пунктта:

икенче абзацта «РФ Законы» сүзләрен «Россия Федерациясе Законы» сүзләренә алмаштырырга;

алтычы абзацта «РФ Президенты указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты указы» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «РФ ГТХМ» сүзләрен «Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «яки шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта икенче җөмләне төшереп калдырырга.

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга бердәм үрнәктәге махсус таныклыклар (таныклыклар дубликатлары) (алга таба – таныклык (таныклык дубликаты) бирү | 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 24 статьясындагы 11 абзацы |
| 2.2. Башкарма хакимият органы исеме | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яисә шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) исеменнән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 228 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 3 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 228 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 7, 10 пунктлары |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга | Таныклык бирү (таныклык бирүдән баш тарту турында) карар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша рәсми мөрәҗәгать җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап 15 эш көне эчендә | |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | гамәлгә ашырыла.<br>Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң егерме бер көнгә кадәр озайтыла.<br>Таныклык (таныклык дубликаты) бирү гариза бирүче таныклык артыннан килгән көнне гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы Россия Федерациясе законнарында каралмаган | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон формадагыларын да, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Таныклык алу өчен:<br>1. Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга ярдәм үрнәктәге махсус таныклыклар бирү турында гариза (Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиоактив пычранган зоналарда яшәү һәм (яки) хәрби хезмәт үтү (хезмәт итү) (торак пункт, адрес, яшәү һәм (яки) хәрби хезмәт үтү (хезмәт итү) сроклары) турында мәгълүматны күрсәтеп)). Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.<br>2. Гариза бирүче ихтыярына карап, гариза бирүченең Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиоактив пычранган зоналарда яшәү һәм (яки) хәрби хезмәт үтү (хезмәт итү) фактын раслаучы документлар:<br>торак-эксплуатация идарәләре, торак-коммуналь бүлекләр архивларыннан өземтәләр;<br>паспорт өстәлләреннән белешмәләр, бүтән документлар.<br>Таныклык дубликатын алу өчен:<br>1. Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга бердәм үрнәктәге махсус таныклыклар бирү турында гариза, анда таныклыкны югалту (бозу) шартлары һәм алу урыны күрсәтелә. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 228 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 4 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | Регламентның 2 нче кушымтасында китерелде.<br>Бозылганы урынына таныклык дубликатын алу өчен мөрәҗәгать иткән гражданнар бозылган таныклыкны күрсәтә.<br>Гариза бирүче Россия Федерациясе гражданины паспортын (яки Россия Федерациясе гражданлыгына караганлыгын раслый торган бүтән төп документларны) күрсәтә. 14 яшенә җитмәгән балалар туу турында таныклык, уллыкка алыну турында таныклык күрсәтә.<br>Гариза бирүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган һәм мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклый торган документны күрсәтә.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның 211 һәм 212 статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:<br>югалган таныклыкның табылмавын раслаучы белешмә (эчке эшләр органнарында); | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 228 |

| | | |
|---|---|---|
| зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | гражданинның Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиоактив пычранган зоналарда яшәү һәм (яки) хәрби хезмәт үтү (хезмәт итү) фактын раслаучы документлар (торак-эксплуатация идарәләре, торак-коммуналь бүлекләр архивларыннан өземтәләр) (әгәр мондый документлар гариза бирүче тарафыннан тапшырылмаса) (вәкаләтле органнардан).<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләрне раслый торган документлар (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>Гариза бирүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Гариза бирүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Идарә (бүлек) гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки | номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 10 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.<br>3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булуы.<br>4. Гариза бирүченең яшәү урыны буенча карамаган Идарәгә (бүлеккә) мөрәҗәгать итүе.<br>5. Почта аша кергән гаризага теркәлеп бирелә торган билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган документларны тапшыру. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>дөрес (төгәл) булмаган мәгълүматларны үз эченә алучы документлар тапшырылу. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый | Россия Федерациясе |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән | Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:<br>Идарә (бүлек) биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында тулы мәгълүматларның булуы;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга инвалидлар өчен бинаның үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүкән бүтән каршылыкларны үтүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары белән расланган тәртипнең 2.4 пункты;<br>Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки файдалана алмау | гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>белгечләрнең Регламентны бозуына карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау;<br>гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән хезмәттәшлек итүе саны;<br>дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлык сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Идарәгә (бүлеккә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, Идарәгә (бүлеккә) | 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты; |

| | | |
|---|---|---|
| Тәтеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84373)<br>2-62-31 | Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районының социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (8552)<br>70-00-57<br>70-13-41 | Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84360)<br>2-18-56 | Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84396)<br>2-57-05<br>2-29-38 | Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84342)<br>5-55-73<br>5-12-06 | Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85593)<br>2-60-41<br>2-82-91 | Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Авиатөзелеш, Яңа Савин районнарында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843)<br>571-58-00<br>(843) 523-3-20 | Usz.Avia@tatar.ru<br>Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Вахитов, Идел буе муниципаль берәмлегенең социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843)<br>238-65-79<br>(843)<br>224-04-20 | Usz.Vahit@tatar.ru<br>Usz.Priv@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| | 224-20-28 | |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Киров, Мәскәү районнарында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843) 554-25-23 | Usz.Kirov@tatar.ru Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Совет районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843) 272-51-79 273-18-06 | Msz.SovOR@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларына аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе җитәкчесе | 264-77-29 | pisma@tatar.ru». |

5. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 19 июлендәге 581 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.07.2016 №438, 08.06.2017 №348, 07.05.2018 №357, 19.09.2018 № 887, 26.07.2019 №580 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Чернобыль һәлакәте

нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтының адресы, Министрлыкның һәм Идарәнең (бүлекнең) электрон почта адресы турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Идарәләрдә (бүлекләрдә) гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

2 пунктчаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре)»;»

1.4.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.5 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы) («Ведомости Съезда народных депутатов и Верховного Совета РСФСР», 1991, № 21, 699 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

алтынчы абзацта «РФ Президенты» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «РФ законнары» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «РФ ГТХМ» сүзләрен «Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта:

өченче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «йә шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта икенче җөмләне төшереп калдырырга.

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы затка таныклык (таныклык дубликаты) (алга таба – таныклык (таныклык дубликаты)) бирү | 1244-1 номерлы РФ Законының 15 ст. 4 п.; Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 727 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 2 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимият органы исеме | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яисә шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) исеменнән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 727 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 3 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 727 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 2, 15 пунктлары |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен | Таныклык бирү (таныклык бирүдән баш тарту турында) карар әлеге | Россия Гадәттән тыш |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша рәсми мөрәҗәгать җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап 15 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң 20 эш көненә кадәр озайтыла.<br>Таныклык (таныклык дубликаты) бирү гариза бирүче таныклык артыннан килгән көнне гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы Россия Федерациясе законнарында каралмаган | хәлләр министрлыгының 727 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 7 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, | Таныклык алу өчен:<br>Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы зат таныклыгы бирү турында гариза. Гаризаның тәкъдим ителгән формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.<br>Гариза бирүче Россия Федерациясе гражданины паспортын күрсәтә.<br>Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:<br>гариза бирүченең 3 x 4 см зурлыгындагы фотосы;<br>читләштерелгән зонада Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә гражданнарның катнашуларын раслаучы документлар арасыннан бер яки берничә документ.<br>Читләштерү зонасында Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә гражданнарның катнашуларын раслаучы документлар:<br>читләшү зонасындагы торак пунктларда (пунктта) булу турындагы | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 727 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 4, 5, 6 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| аларны тапшыру тәртибе | тамгалы командировка таныклыгы;<br>1986-1990 елларда турыдан-туры читләштерелгән зонада эшләр башкарган предприятие, оешма, учреждение, хәрби частьләр; СССР Гражданнар оборонасы штабы тарафыннан, тиешле архивлардан бирелгән читләштерү зонасындагы эшләрдә катнашу турында белешмә;<br>читләшү зонасында эшләү турындагы язу белән хезмәт кенәгәсе («Эш турында мәгълүматлар» бүлеге);<br>читләшү зонасында эш вакытын исәпкә алу табеле;<br>читләшү зонасында (читләшү зонасы эчендәге куркыныч зоналарда) эшләгән өчен хезмәткә түләүнең (арттырылган күләмдә акчалата түләүләр турында) арттырылган күләменә хокук турында белешмә;<br>читләшү зонасына очу өчен биремнәр (заявка), очу кенәгәсе һәм читләшү зонасына очу турында язулар белән очу-күтәртү составының очыш кәгазьләре;<br>хәрби билет («Өйрәнү җыеннарын узу» һәм «Махсус билгеләр» бүлекләре), Чернобыль АЭС авария (читләшү зонасында) нәтиҗәләрен бетерү эше турындагы язу белән;<br>Чернобыль АЭС һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан хәрби частьнең шәхси составы буенча, читләшү зонасына килеп җитүе, китүе һәм эшләве турында боерыктан өземтә;<br>1986-1990 елларда читләшү зонасында Чернобыль АЭС һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашу һәм анда булу сроклары турында СССР Дәүләт иминилеге комитетының хәрби хезмәткәрләрне командировкага җибәрү турында куркынычсызлык (дәүләт иминлеге) органы башыгының шәхси составы буенча боерыгыннан өземтә.<br>«Укрытие» объекты буенча эшләрдә катнашуны раслый торган документлар (әлеге объект буенча эш турында күрсәтеп):<br>Чернобыль АЭС авария нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан һәм Шәхси составы авария нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә катнашкан (хезмәт бурычларын үтәгән) хәрби частьләр исемлегенә кертелгән хәрби | |

| | | |
|---|---|---|
| | частьләр буенча «Укрытие» объекында эшләр башкару өчен юллау турында тиешле архивтан боерык өземтәсе;<br>«Укрытие» объектына бару буенча дозиметрлар бирү һәм дозаларны тикшерүдә тоту буенча журналлардан өземтә; «Укрытие» объектында эшләр башкаруга рөхсәт кәгазеннән өземтә; тиешле эшләрне алып бару өчен «Укрытие» объектына пропуск кәгазе: 1987 елның июленнән 31 декабренә кадәр «Шлем» шифры белән («буденновка» рәсеме); 1989 елның 1 гыйнварыннан «Тубус» шифры белән (микроскоп рәсеме); 1989 елның 1 гыйнварыннан 3 төркем пропусклары буенча һәм «Птица» шифры белән (канатлары күтәртелгән кош рәсеме) (пропусклардан гайре документлар Чернобыль АЭС администрациясенең герблы мөһере белән яки И.В.Курчатов исемендәге институтның комплекслы экспедициясе, яки «Комбинат» ҖБ тарафыннан яки аларның әлеге документларны биргән тиешле хезмәтләре тарафыннан таныкланган булырга тиеш);<br>Чернобыль АЭС администрацияләреннән яки И.В.Курчатов исемендәге институтның комплекслы экспедициясеннән, яки «Укрытие» тармакара фәнни-техник үзәгеннән, Украинаның Милли фәннәр академиясеннән (И.В.Курчатов исемендәге институтның комплекслы экспедициясенең хокуклы варисы) бирелгән, «Укрытие» объектында эшләү вакыты турында белешмә, «Укрытие» объектында эшләү вакытына карый торган эш вакытын исәпкә алу табеле, «Укрытие» объектындагы эшләргә караган хезмәткә түләү турында белешмәләр (документлар Чернобыль АЭС администрациясенең герблы мөһере белән яки И.В.Курчатов исемендәге институтның комплекслы экспедициясе, яки «Комбинат» ҖБ тарафыннан яки аларның әлеге документларны биргән тиешле хезмәтләре тарафыннан таныкланган булырга тиеш).<br>1988-1990 елларда «Укрытие» объекты буенча эшләр дигәндә, анда булу вакытына һәм алынган доза йөкләнешенә бәйсез рәвештә, | |

| | | |
|---|---|---|
| | Чернобыль АЭС 4 нче энергоблогында яклагыч корылма эчендәге барлык эшләр, шулай ук «Укрытие» объектын саклау буенча 15-19 нчы номерлы постларда эчке гаскәрләрнең хәрби хезмәткәрләре тарафыннан хәрби хезмәтне гамәлдә узу, постларда хезмәт үтүне һәм доза йөкләнешләре дәрәҗәләрен контрольдә тоту һәм күрсәтелгән постлар белән чикләнгән периметры буенча «Укрытие» объектын инженер-техник саклау чараларын тикшерү эшләре турында аңлатыла.<br>Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:<br>үлгән гражданинның элек яки әлеге Регламент нигезендә бирелгән таныклыгы (таныклык булмаган очракта, үлгән гражданинның шәхси эшеннән читләшү зонасында эшләр башкарганлыгын раслый торган бер яки берничә документ, ә алар шәхси эштә булмаган очракта – әлеге Регламентта югарыда санап үтелгән документлар);<br>Кирәк булган очракларда гражданнар әлеге таныклыкны алу хокукына ия булган зат белән туганлык элемтәләрен раслаучы документларны; уллыкка алу турында таныклыкны; шәхесне раслаучы һәм гражданлыкка күрсәтә торган башка документларны тапшыра.<br>Таныклык дубликатын алу өчен:<br>Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы зат таныклыгы дубликатын бирү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган формасы, таныклыкны югалту яки бозу шартларын аңлатып һәм аны беренчел документлар нигезендә алу урынын күрсәтеп, әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән;<br>гариза бирүченең 3 x 4 см зурлыгында фотосы (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өчен).<br>Элегрәк бирелгән таныклык яраксызга чыккан очракта, бозылган таныклык та тапшырыла.<br>Гариза бирүче Россия Федерациясе гражданины паспортын күрсәтә.<br>Гариза бирүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган | |

| | | |
|---|---|---|
| | очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүчеләрнең мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхес таныклаучы документ күчермәсеннән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылырга яисә почта юлламасы итеп кулга тапшыру турында белдерү белән җибәрелергә мөмкин.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:<br>югалган таныклыкның табылмавын раслый торган белешмә (эчке эшләр органнарыннан);<br>Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 727 номерлы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | пенсия алу факты турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);<br>балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан);<br>гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (гражданлык хәле актларын теркәү органнары органнарыннан);<br>тукландыручының вафат булуы турында белешмәләр (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан);<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләрне раслый торган документлар (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан).<br>Күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры да алынырга мөмкин, шул исәптән мондый мөмкинлек булганда – электрон рәвештә.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Идарә (бүлек) гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче | белән расланган тәртипнең 15 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.<br>3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булуы.<br>4. Гариза бирүченең яшәү урыны буенча Идарәгә (бүлеккә) мөрәҗәгать итүе | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Ялган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торучы документларны тапшыру дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый | Россия Федерациясе |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле | |

| | | |
|---|---|---|
| исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән | Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:<br>Идарә (бүлек) биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, чорлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында тулы мәгълүматлар булуы;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга инвалидлар өчен бинаның үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр | 880 номерлы ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 2.4 п.;<br>Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки файдалана алмау | алуга комачау итүкән бүтән каршылыкларны үтүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>белгечләрнең Регламентны бозуына карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау;<br>гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән хезмәттәшлек итүе саны;<br>дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлык сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Идарәгә (бүлеккә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, Идарәгә (бүлеккә) гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш | 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары»; |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип таныргa;

3.3.2 пунктның дүртенче абзацында «2.8» саннарын «2.7» саннарына алмаштырырга;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү, мәгълүматлар алу

Идарә (бүлек) белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан дәүләт хезмәте алучыга пенсия билгеләү турында;

балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләрне – гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан;

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр – гражданлык хәле актларын теркәү органнары органнарыннан;

тукландыручының вафат булуы турында – гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан;

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләрне раслый торган документлар – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан.

Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Идарәдә (бүлектә) булмаганда, Идарә (бүлек) белгече, шул исәптән электрон рәвештә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Россия Федерациясе Пенсия фондына – дәүләт хезмәте алучыга пенсия билгеләү турында;

балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарына;

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарына;

тукландыручының вафат булуы турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарына;

эчке эшләр органнарыннан югалган таныклыкның табылмавын раслаучы белешмәләрне (мөрәҗәгать итүче таныклык дубликатын алу буенча мөрәҗәгать иткән очракта);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләрне раслый торган документлар (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган белешмәләр, мәгълүматлар һәм белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.5.1 пунктта:

3.5.1 пунктта һәм аннан соң текст буенча «вакыттан башлап» сүзләрен «көннән башлап» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.6.3 пунктның өченче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.6.7 пунктның бишенче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.7.2 пунктның беренче абзацында «Нигезләмәнең» сүзен «Тәртипнең» сүзенә алмаштырырга;

3.8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.9 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«3.9. Техник хата төзәтү

Элек бирелгән таныклыкта (таныклык дубликатында) җибәрелгән техник хаталарны бетерүгә бәйле рәвештә таныклыкны (таныклык дубликатын) яңадан рәсмиләштерү техник хатасы булган, Идарә (бүлек) белгече тарафыннан гариза килгән көнне кабул ителгән һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәлгән таныклык (таныклык дубликаты) белән бергә тапшырылган гариза (киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.9.1. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турындагы үтенеч кәгазен Министрлыкка җибәрү

Идарә (бүлек) белгече гариза һәм техник хатасы булган таныклык (таныклык дубликаты) нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

таныклык (таныклык дубликаты) бирүгә исемлек (алга таба – исемлек) формалаштыра (Исемлекнең формасы Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 727 номерлы боерыгы белән расланган нигезләмәнең 4 нче кушымтасында китерелгән);

таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенеч кәгазе проектын әзерли (алга таба– үтенеч кәгазе);

Идарә (бүлек) җитәкчесенә кул кую өчен гаризаны һәм исемлек проектын җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенеч проекты, исемлек.

3.9.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе гаризаны һәм техник хатасы булган таныклыкны (таныклык дубликатын) караганнан соң, таныклык (таныклык дубликатын) бирү турындагы үтенеч кәгазенә һәм исемлеккә кул куя.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында имзаланган үтенеч кәгазе һәм исемлек.

3.9.3. Идарә (бүлек) белгече таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында гаризаны һәм исемлекне Министрлыкка юллый.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкка юлланган, таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенеч язуы һәм, техник хатасы булган таныклыкны (таныклык дубликатын) теркәп, исемлек

3.9.4. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар кабул итү

Министрлыкның эш башкару бүлеге белгече Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон Хөкүмәт» электрон документлар әйләнеше системасында Идарәдән (бүлектән) кергән үтенечне терки һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Идарәдән (бүлектән) документлар кергән көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: үтенеч, таныклык бланкы теркәлгән исемлек.

3.9.5. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар проектын рәсмиләштерә;

таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар проектын имзалау өчен министрга җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар Министрлыкта үтенеч теркәлгән көннән соң сигез эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар проекты.

3.9.6. Алга таба административ процедуралар әлеге Регламентның 3.6.5 - 3.6.12, 3.7.1 - 3.7.2 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлектә:

4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору Министрлыкның социаль ярдәм чаралары методолгиясе бүлеге җитәкчесе, Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләре үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«4.2. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Идарә (бүлек) хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.8 пунктта «хезмәткәр» сүзен «Учреждение белгече» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүмат

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85551)<br>2-10-86<br>2-11-53 | Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85592)<br>7-25-10<br>7-14-25 | Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84344)<br>2-92-72<br>2-92-74 | Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85552)<br>3-11-46<br>3-12-81 | Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84341)<br>2-41-40<br>2-46-46 | Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84346)<br>2-08-90<br>2-08-80 | Usz.Alkeevo@tatar.ru |
| Әлмәт муниципаль районы социаль яклау идарәсе җитәкчесе | (8553)<br>32-45-50<br>43-82-15 | Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84376)<br>2-12-84 | Usz.Apastovo@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| | 2-10-81 | |
| Арча муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84366)<br>3-13-53<br>3-13-33 | Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84369)<br>2-16-60<br>2-10-84 | Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85569)<br>5-10-50<br>5-66-81 | 423930, г. Бавлы, пл. Победы, д. 4<br>Usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84368)<br>2-44-78<br>2-42-09<br>2-50-57<br>2-40-60 | Usz.Baltasi@tatar.ru |
| Бөгелмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85594)<br>6-50-44<br>6-55-70 | Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84374)<br>3-32-10<br>3-55-29 | Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84379)<br>2-17-57<br>2-22-76 | Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84365)<br>7-47-69<br>7-47-89 | Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84375)<br>2-38-07<br>2-30-07 | Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85557)<br>7-84-66<br>7-86-91 | Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85558)<br>7-10-64 | Usz.Zainsk@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| | 7-09-76<br>3-26-89 | |
| Зеленодольск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84371)<br>5-58-80<br>4-16-62<br>4-22-97 | Usz.Zeldol@tatar.ru |
| Кайбыч муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84370)<br>2-11-12<br>2-15-57 | Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама Тамагы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-69 | Usz.K-uste@tatar.ru |
| Кукмара муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84378)<br>2-49-70<br>2-47-31 | Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85595)<br>5-07-51<br>5-50-03 | Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85563)<br>3-12-36<br>3-19-69 | Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85549)<br>2-23-00 | Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85555)<br>3-26-59<br>3-19-08 | Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85556)<br>2-57-37<br>2-57-69 | Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә социаль яклау идарәсе җитәкчесе | (8552)<br>53-60-33 | Usz.Chelny@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Түбән Кама муниципаль районы социаль яклау идарәсе җитәкчесе | (8555)<br>45-39-20<br>45-43-86<br>45-43-88<br>45-35-02 | Usz.Nizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84348)<br>2-41-18<br>2-41-42 | Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84345)<br>2-06-62<br>2-06-81<br>2-39-88 | Usz.Nurlat@tatar.ru |
| Питрәч муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84367)<br>3-06-68<br>3-02-78<br>3-00-15 | Usz.Pitriash@tatar.ru |
| Балык Бистәсе муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84361)<br>2-11-57<br>2-39-62 | Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84362)<br>2-28-11<br>2-28-55 | Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85559)<br>2-45-72<br>2-44-37<br>2-49-87 | Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84347)<br>3-00-00<br>3-08-98 | Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84373)<br>2-62-31 | Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районының социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (8552)<br>70-00-57<br>70-13-41 | Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84360)<br>2-18-56 | Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районында | (84396) | Usz.Cheremshan@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| социаль яклау бүлеге җитәкчесе | 2-57-05<br>2-29-38 | |
| Чистай муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (84342)<br>5-55-73<br>5-12-06 | Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (85593)<br>2-60-41<br>2-82-91 | Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Авиатөзелеш, Яңа Савин районнарында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843)<br>571-58-00<br>(843)<br>523-3-20 | Usz.Avia@tatar.ru<br>Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Вахитов, Идел буе муниципаль берәмлегенең социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843)<br>238-65-79<br>(843)<br>224-04-20<br>224-20-28 | Usz.Vahit@tatar.ru<br>Usz.Priv@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Киров, Мәскәү районнарында социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843)<br>554-25-23 | Usz.Kirov@tatar.ru<br>Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Совет районы социаль яклау бүлеге җитәкчесе | (843)<br>272-51-79<br>273-18-06 | Msz.SovOR@tatar.ru |

## 2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларына аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе җитәкчесе | 264-77-29 | pisma@tatar.ru». |